**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨЧКУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

17.02.2023 ел №71-2

Спас муниципаль районы Өчкул авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 июнендәге 113 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкул авыл җирлеге үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында ялган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары кертү хакындагы тәртипкә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә, ТР Спас муниципаль районының Өчкул авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Спас муниципаль районы Өчкул авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 июнендәге 113 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкул авыл җирлеге үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында ялган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары кертү хакындагы тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 2 пунктның икенче абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның икенче абзацында, 6 пунктның беренче абзацларында, 7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында «Президент» сүзен «Башлык (Рәис)»сүзләре белән алыштырырга.

1.2 11 пунктның 2 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыгына-(Рәискә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Өчкул авыл җирлеге башлыгы Н.В. Емелюшина